Фамилиягез ___________________________
Исемегез _____________________________
Әтиегезнең исеме _____________________

Номерыгыз [ ]

# ТЫҢЛАП АҢЛАУ

Башлангыч дәрәҗә: B1.

**30 минут**

## Биремнәр бланкы

### Эшне башкару өчен күрсәтмә

Биремнәр бланкының өске өлешенә фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исемен һәм номерыгызны языгыз. Шул ук мәгълүматларны җаваплар бланкының өске өлешенә язып куегыз.
Сез җавап вариантларыгызны биремнәр бланкында да билгели аласыз. Биремнәрне эшләп бетергәч, җавапларыгызны махсус бланкка күчереп язарга онытмагыз. Инструктор биремнәрне эшләп бетерергә 10 минут кала сигнал бирәчәк.
Һәр бүлек башында эшне башкару өчен күрсәтмә һәм үрнәк бирелгән. Сез барлык биремнәрне үтәргә тиеш.
Биремнәрне эшләп бетергәч, биремнәр һәм җаваплар язылган бланкларны инструкторга бирегез.

### Тест турында кыскача мәгълүмат

Биремнәрне эшләү вакыты: 30 минут
Бүлекләр саны: 4
Биремнәр саны: 25
Баллар: һәр бирем 1 балл белән бәяләнә.
Гомуми баллар саны: 25

# ТЫҢЛАП АҢЛАУ ТЕСТЫ

**1 нче бүлек.**

**Сез җиде кыска диалог тыңларсыз. 1-7 нче сорауларга туры килгән җавапны үрнәктәгечә билгеләгез. Сез аудиоязманы ике тапкыр тыңларсыз.**

**ҮРНӘК** **Әнәс чаңгы ботинкаларын кайдан алган?**

**(1)** Туганы бүләк иткән.
2) Спорт кирәк-яраклары бүлегеннән алган.
3) Икенче каттагы кибеттән алган.

**1** **Дуслар кайсы кафега киткәннәр?**

1) «Чәй» кафесына
2) «Кунакчыл» кафесына
3) «Тәмле» кафесына

**2** **Дусларына кайсы рәттән урын табылган?**

1) Унсигезенче
2) Уналтынчы
3) Ундүртенче

**3** **Бакчага ничә кеше барган?**

1) Алты
2) Биш
3) Дүрт

**4** **Гөл кайсы бүлмәдә тора?**

1) Алгы бүлмәдә
2) Йокы бүлмәсендә
3) Аш бүлмәсендә

**5** **Бу атнада Сынлы сәнгать музеенда нинди күргәзмә уза?**

1) «Гасырлар авазы»
2) «Киң Идел»
3) «Диңгездә»

**6** **Ханымның чемоданы нинди?**

1) Ике тәгәрмәчле һәм озыная торган тоткычлы
2) Дүрт тәгәрмәчле һәм каешлы
3) Ике ягыннан да тәгәрмәчле һәм озын тоткычлы

**7** **Әфәнденең самолеты сәгать ничәдә оча?**

1) 7.15

2) 7.35
3) 8.45

**2 нче бүлек.**

**Гайсә Маликов белән интервьюны тыңлагыз. 8-13 нче биремнәргә туры килгән җавапны сайлагыз. Сез интервьюны ике тапкыр тыңларсыз.**

**8** **Гайсә кечкенәдән ...**
1) музыкант булырга теләгән.
2) укытучы булырга теләгән.
3) ил башлыгы булырга теләгән.

**9** **Гайсә фикеренчә, егетләр ...**
1) хәрби оркестрда хезмәт итәләр.
2) эштән куркалар.
3) хәрби хезмәттән качмаска тиеш.

**10** **Ул консерваториянең симфоник оркестры белән**
1) Европада гастрольләрдә булган.
2) Венега ял итәргә барган.
3) Эстониядә халык җырлары фестивалендә катнашкан.

**11** **Гайсә эстрада концертларында ...**
1) җырлый һәм бии, музыка коралында уйнамый.
2) җырлый, бии, нәфис сүз сөйләми.
3) җырламый, бии, музыка коралында уйный.

**12** **Гайсә буш вакытында ...**
1) спорт белән шөгыльләнергә ярата.
2) клубларга ялгызы йөрергә ярата.
3) машина йөртергә ярата.

**13** **Киләчәктә Гайсә ...**
1) чит илдә эшләргә тели.
2) укуын дәвам итәргә уйлый.
3) җырчы булырга хыяллана.

**3 нче бүлек.**

**Конкурс турында белдерүне тыңлагыз. 14-19 нчы биремнәрдәге буш урыннарга туры килгән мәгълүматны бер яки ике сүз, символ белән языгыз. Сез белдерүне ике тапкыр тыңларсыз.**

**«Иң яхшы фотосурәт» конкурсы**

14 **Беренче бүләк**: 2000 сум һәм ................. сурәтләнгән картина.

**Икенче бүләк:** 1000 сум һәм кыйммәтле фотоаппарат.

**15** **Конкурсның тәмамлану көне**: ......................
(көн, ай)

**16** **Темалары:** 1 – Татарстанның табигате
2 – Җирнең серле урыннары
3 – ...................... серләр

**Күргәзмә үткәрү урыны:** Сынлы сәнгать музее

**17** **Күргәзмә уздырылачак шәһәрләр:** Казан, Мамадыш, ......, Бөгелмә, Тула һәм Самара.

**18** **Конкурсны үткәрү урыны**: Казан шәһәре, Габдулла............. урамы, 91 нче йорт, “Курай” радиосы.

**19** **Элемтә өчен телефон**: 5-...-50- 1..
(сан белән язарга)

**4 нче бүлек.**

**Ике дусның сөйләшүен тыңлагыз. 20-25 нче биремнәрдәге раслауларның текстка туры килүен (1) яки туры килмәвен (2) билгеләгез. Сез диалогны ике тапкыр тыңларсыз.**

**20** Мөнирә биш яшьтән бирле спорт мәктәбенә йөргән.
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**21** Мөнирә һәр көнне спорт белән шөгыльләнә.
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**22** Мөнирә Германиядә үткәрелгән беренчелектә быел диплом ала.
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**23** Самат компьютер программалары төзү белән кызыксына.
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**24** Саматның укытучылары – Казан федераль университеты профессорлары.
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**25** Самат Германиягә халыкара олимпиадага барган.
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**Җавапларны махсус бланкка күчерү өчен, 6 минут вакытыгыз бар.**

Фамилиягез ________________________
Исемегез ___________________________
Әтиегезнең исеме __________________

Номерыгыз [ ]

# УКУ ҺӘМ ЯЗУ

Башлангыч дәрәҗә: B1.

**1 сәгать 30 минут**

## Биремнәр бланкы

**Эшне башкару өчен күрсәтмә**

Биремнәр бланкының өске өлешенә фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исемен һәм номерыгызны языгыз. Шул ук мәгълүматларны җаваплар бланкының өске өлешенә язып куегыз.

Сез җавап вариантларыгызны биремнәр бланкында да билгели аласыз. Биремнәрне эшләп бетергәч, җавапларыгызны махсус бланкка күчереп язарга онытмагыз. Инструктор биремнәрне эшләп бетерергә 10 минут кала сигнал бирәчәк.

Һәр бүлек башында эшне башкару өчен күрсәтмә һәм үрнәк бирелгән. Сез барлык биремнәрне үтәргә тиеш.

Биремнәрне эшләп бетергәч, биремнәр һәм җаваплар язылган бланкларны инструкторга бирегез.

Сорауларыгыз булса, Сез аларны хәзер бирә аласыз. Биремнәрне эшләгәндә, сораулар бирү һәм сөйләшү тыела.

**Тест турында кыскача мәгълүмат**

Биремнәрне эшләү вакыты: 1 сәгать 30 минут
Бүлекләр саны: 7
Биремнәр саны: 41
Баллар: һәр бирем – 1 балл, 41 нчы бирем 10 балл белән бәяләнә.
Гомуми баллар саны: 50

# УКУ

## 1 нче бүлек

**1-5 биремнәрдәге текстларны укыгыз. Куелган сорауга туры килгән җавапны үрнәктәгечә билгеләгез.**

**Үрнәк:**

**ҮРНӘК**

Су керүчеләр игътибарына!
Сак булыгыз! Монда су керү тыела, чөнки суның сыйфаты начар.

**Бу белдерү нәрсә турында?**

1) Биредә су керергә киңәш итмибез.

**(2)** Бу урында су керергә ярамый, чөнки су пычрак.

3) Су керәсегез килсә, башка урын тәкъдим итәбез.

---

**1**

Сәлам, Азат! Җәен сиңа кунакка килергә телим. Июль аенда мин ялга чыгам. Син бу вакытта Казанда буласыңмы? Миңа шәһәр күрсәтергә вакытың булырмы? Синнән җавап көтәм.

Дустың Алмаз

**Алмаз дустыннан нәрсә белергә теләгән?**

1) Дустының җәйге ялы турында беләсе килгән.

2) Дустының кунакка килүе турында белергә теләгән.

3) Дустының җәен шәһәрдә булуын ачыклыйсы килгән.

**2**

Укучылар!
Әгәр сез шигърият белән кызыксынсагыз, әдәби түгәрәк утырышына килегез. Сишәмбе көнне алтынчы дәрестән соң татар теле кабинетына чакырабыз.

**Белдерүдә сүз нәрсә турында бара?**

1) Шигърияткә багышланган дәрес үткәрү турында.

2**)** Шигърият яратучыларны чакыру турында.

3) Татар теле дәресеннән соң үткәрелә торган шигърият кичәсе турында.

| | | |
|---|---|---|
| **3** | Мансур, сиңа дустың Марат шалтыратты һәм иртәгә мәктәптә чаңгы ярышы булуы турында хәбәр итте. Сәгать тугызда мәктәп янында булырга кирәк.<br>Әниең | **Бу язу нәрсә турында?**<br>1) Марат дустының әнисенә хәбәр җиткергән.<br>2) Марат дусты Мансурга шалтыраткан.<br>3) Марат Мансурга чаңгы ярышы турында язган. |
| **4** | Игътибар! Игътибар! Иртәгә шәһәребезнең Мәдәният сараенда яшь рәссамнар күргәзмәсе ачыла. Мәктәп укучыларын, студентларны әлегә тантанага чакырабыз һәм көтеп калабыз. | **Бу белдерүдә нәрсә турында язылган?**<br>1) Яшь рәссамнар күргәзмәсендә укучылар катнашуы турында.<br>2) Мәдәният Сараена киләчәк рәссамнар турында.<br>3) Тантанага яшьләрне чакыру турында. |
| **5** | Сәлам, Мәдинә. Бу – сыйныфташың Алсу. Хәлләреңне беләсем килә. Барысы да яхшымы? Хастаханәдә табиблар ничек дәвалыйлар? Иртәгә синең яныңа килергә җыенам, сиңа нәрсә дә булса кирәкме? Кирәк булса, СМС җибәр. | **Алсу дустыннан нәрсә турында сораган?**<br>1) Табибларның исемнәрен белүе турында.<br>2) Сыйныфташларының хастаханәгә килүе турында.<br>3) Дустына кирәкле әйберләр турында. |

**2 нче бүлек.**

**6-10 нчы текстлардагы кешеләрнең тасвирламаларын һәм 1-8 нче текстлардагы Интернет сайтларының тасвирламаларын тәңгәл китерегез. Интернет сайтлар турында өч артык текст булуы турында онытмагыз.**

**6** Әминә кечкенәдән телләр белән кызыксына. Хәзерге вакытта ул мәктәптә татар, рус һәм инглиз телләрен өйрәнә. Киләчәктә Әминәнең башка телләрне дә үзләштерәсе килә. Мәсәлән, кытай яки япон телләрен. Ул шундый онлайн-курсларны эзли.

**7** Энҗенең әнисе – тәрҗемәче. Энҗенең киләчәктә әнисе кебек тәрҗемәче буласы килә. Шуңа да ул, инглиз теленнән тыш, испан телен өйрәнә башлаган. Аңа бу телне яхшы белү өчен, кулланмалар кирәк.

**8** Кәрим истәлекле урыннарның тарихы белән кызыксына. Мәктәптә тарих укытучысы аны бик мактый, чөнки Кәрим күп укый, күп белә. Күптән түгел укытучысы аңа республикабыз тормышындагы истәлекле вакыйгаларга багышланган бәйгедә катнашырга тәкъдим иткән.

**9** Булатның борынгы һәм заманча шәһәрләр, аларда яшәгән кешеләр турында күп беләсе килә, шуңа күрә ул Интернеттан алар турында мәгълүмат җыя. Шундый шәһәрләр арасында Казан, Алабуга да бар. Алар меңьеллык юбилейларын бәйрәм иттеләр. Булат алар турында укучылар конференциясендә чыгыш ясарга җыена.

**10** Татар теле укытучысы укучыларга дөнья телләре турында чыгыш әзерләп килергә куша. Моның өчен төрле чыганаклардан файдаланырга киңәш бирә. Һәр укучы үз чыгышында киң таралган телләр турында да, юкка чыгу куркынычы янаган телләр турында да сөйләргә тиеш.

## Интернет сайтлары

### 1) Бергәләп өйрәник!

Чит телләрне өйрәнәсегез килсә, безнең сайттан файдаланыгыз. Биредә, Европа телләрен башлап өйрәнү өчен, бөтен мөмкинлекләр булдырылган. Монда сез, яңа чыккан китаплар, сөйләүлекләр, сүзлекләр, үзөйрәткечләр белән таныша һәм аларны үзегезгә алдыра аласыз.

### 2) Тарих белән кызыксынучыларга

"Тарихтан иң яхшы эссе" конкурсында катнашу өчен, http://belem.ru адресына эшләрегезне җибәрүегезне сорыйбыз. Анда бирелгән таләпләр белән танышып чыгыгыз һәм эшегезне шуларга

нигезләнеп языгыз. Исегезгә төшерәбез: җибәргән эшегез бары тик туган ягыгызның тарихына бәйле булырга тиеш.

**3) Укучылар игътибарына**

Безнең журналның сайтында сез күп кызыклы тарихи мәгълүмат таба аласыз. Журнал битләрендә татар халкының күренекле шәхесләре, аларның иҗаты һәм ирешкән уңышлары турында язмалар урнаштырыла. Үзегезне кызыксындырган сорауларны да безгә юллый аласыз.

**4) Телләр күп...**

Лингвопедия сайтында сезне кызыксындырган күп нәрсәне табарга мөмкин. Телләрне ничек бүләләр, аларның кайсылары күбрәк кулланыла, кайсыларында бик аз гына кеше сөйләшә, телләрне өйрәнү өчен нәрсәләр мөһим кебек сорауларыгызга тулы җавап таба алырсыз.

**5) Кем буласың килә: тарихчымы, тәрҗемәчеме...**

Танылган рәссам Пабло Пикассоның иң беренче сүзе "карандаш" (испанча "lapiz") булган, диләр. Димәк, баланың кем буласын туганда ук белергә мөмкин. Әгәр ул кечкенәдән буяу, рәсем ясау белән кызыксынса, әлбәттә, әти-әнисе аны сәнгать мәктәбенә йөртү турында уйлый. Безнең сайт сезгә бу юнәлештә ярдәм итәр.

**6) Тарихка күз салсак**

Борынгы цивилизацияләр, аларның башкалалары, бүгенге мегаполислар турында беләсегез килсә, безнең сәхифәләребезгә мөрәҗәгать итегез. Бу сайтта төрле чорларда яшәгән халыкларның тормышы, мәдәнияте, сәнгате, милли үзенчәлекләре турында күпсанлы мисаллар табарсыз, белемнәрегезне баетырсыз.

**7) Телләр беләсең килсә...**

Телләр өйрәнү турында сөйләшкәндә, без күбрәк инглиз, алман яки француз телләрен истә тотабыз. Ә бит көнчыгыш телләрен өйрәнү хәзерге вакытта бик мөһим. Шуңа күрә бу телләрне белергә теләсәгез, безгә мөрәҗәгать итегез. Бездә иң тәҗрибәле укытучылар эшли.

**8) Укучыларны чакырабыз!**

2015 нче елда Татарстан Республикасы Милли китапханәсе олуг юбилеен бәйрәм итә. Аның оешуына йөз илле ел тула. Бу вакыйгага

бәйле төрле чаралар үткәрелә. Китапханәбезнең тарихын искә төшерү өчен, мәктәп укучыларын юбилейга багышланган онлайн-викторинада катнашырга чакырабыз.

**3 нче бүлек.**

**Текстны укыгыз. 11-20 нче биремнәрдәге раслауларның текстка туры килүен (1), туры килмәвен (2) билгеләгез.**

### Кызыл китап

Борын заманнан бирле шулай: кеше гомер-гомергә табигать белән көрәшкән, табигатьтән курыккан. Хәзер исә табигать аның үзеннән курка бугай...

Галимнәр исәпләп караганнар да коточкыч «яңалык» ачканнар: соңгы өч йөз илле ел дәвамында җәнлек-хайваннарның алтмыш төре һәм кошларның йөзгә якын төре юкка чыгарылган. Шуларның өчтән бере — соңгы илле ел эчендә!

Африка филләренең озын ак тешләре бильярд шарлары ясарга әйбәт икән, аларны шул тешләре өчен аулаганнар. 1741 нче елда Камчатка тирәсендәге утраулар билгеле була. Утрауларда зур гәүдәле сәер хайваннар очраган. Алар кит кебек тә түгел, балыкка да охшамаганнар, ди. Әмма итләре бик тәмле булган. Бу хайваннарны диңгез сыерлары дип атаганнар. Диңгез сыерлары, зур-зур көтүләргә тупланып, яр буйларында яшәгәннәр. Аларның озынлыгы сигез метр, авырлыгы дүрт тоннага якын була. Хайваннар су үсемлекләре белән тукланганнар. Аларны аулау, күрәсең, бик ансат булгандыр: 1768 нче елда бу төрнең соңгы вәкиле үтерелә. Шулай итеп, егерме җиде ел үтүгә, Командор утрауларындагы диңгез сыерларының берсе дә калмый.

Һинд океаны утрауларында дронт дигән кошлар яшәгән. Дошманнары булмаганга күрә, алар очу сәләтен бөтенләй югалтканнар. Утрауга кешеләр килгәч, алар йөгереп качарга теләгәннәр, әмма котыла алмаганнар.

Америка далаларында бизоннар көтүләп йөргән. Аларның гомуми саны сиксән миллионга якын булган. Яңа Дөньяны яулап алу вакытында алар юкка чыкканнар. Поездлар билгеле бер урыннарда туктаган да, пассажирлар, вагон тәрәзәсеннән үрелеп, мылтыклардан атканнар. Нәтиҗәдә, миллионлаган кыргый үгезләрдән хәзер берничә йөз бизон гына калган, алары да тыюлыкларда гына әле.

1918 нче елда соңгы тарпанны — Европа далаларында яшәүче кыргый атны һәлак итәләр.

Үсемлекләр дөньясы да зур зыян күрә. Кайбер үләннәр, агачлар бөтенләй юкка чыккан. Үсемлек, хайван, кош-кортларның бетә баруы — фән өчен генә түгел, табигать өчен дә зур югалту. Шәһәрләр җимерелсә, кабат төзеп була. Ә менә юкка чыккан хайваннарны яңадан терелтә алмыйсың. Шуңа күрә Җирдәге тереклекне сакларга кирәк.

Галимнәр бу хакта бик күп уйланалар һәм 1948 нче елда, югалып бара торган хайваннарны, үсемлекләрне өйрәнү өчен, Халыкара комиссия оештыралар. Комиссия төрле материклардагы сирәк очрый торган хайваннар, үсемлекләр турында мәгълүматлар җыя һәм исемлек төзи. Комиссиянең рәисе инглиз зоологы Питер Скотт тәкъдиме белән 1963 нче елда Халыкара Кызыл китап булдырыла. 1978 нче елда безнең илебездә дә Кызыл китап дөнья күрә. Аннан соң төрле республикаларда да шундый ук китаплар языла башлый. Татарстанның Кызыл китабы исә 1995 нче елда төзелә.

Кызыл китапның битләре төрле төстә.

*Кызыл битләргә* теркәлгән төрләрнең хәле аеруча аяныч. *Сары битләрдә* кими бара торган төрләр язылган. *Ак битләрдә* исә сирәк очрый торган хайваннар һәм үсемлекләрнең исемнәре теркәлгән. Аларга куркыныч янамый, ләкин алар бик аз санда калган. *Яшел битләрдә* исә үрчеп-күбәеп киткән төрләрнең исемнәрен укыйсың. Яшел битләр елдан-ел күбәя. Бу кешенең табигатькә ярдәм итә алуын күрсәтә. Һәр ил үз җирендә яшәүче сирәк төрләрнең саклануы өчен кешелек алдында җавап бирә.

**11** **Соңгы гасырларда табигатькә зур зыян китерелгән, җәнлекләрнең йөзгә якын төре үтерелгән.**
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**12** **Зур гәүдәле сәер хайваннарны аулау җиңел булган.**
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**13** **XVIII гасырда диңгез сыерларын саклап кала алмаганнар.**
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**14** **Бүгенге көндә кыргый үгезләрнең саны миллионга җитә.**
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**15** **Кыргый атларны хәзерге вакытта тыюлыкта гына күреп була.**

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**16** **Тереклекне бетерү җиңел, ләкин кире терелтеп булмый шул.**

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**17** **Халыкара комиссия төрле галимнәр тәкъдиме нәтиҗәсендә төзелә.**

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**18** **Комиссиянең эше белән алман галиме җитәкчелек итә.**

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**19** **Кызыл китапның битләре биш төсле.**

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**20** **Һәр дәүләт көч куймаса, юкка чыгу куркынычы янаган төрләрне саклап калып булмас.**

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**4 нче бүлек**

**Текстны укыгыз. 21-25 нче биремнәрдәге сорауларны укыгыз һәм туры килгән җавапны билгеләгез.**

### Нурихан Фәттах истәлекләреннән

Иң беренче шигыремне мин өченче класста укыганда яздым. Кыш көне иде. Дәрестән соң елга янында, чаңгы шуып, туңып кайттым да күңелле, шатлыклы хисләрне кәгазьгә язмакчы булдым. Шигыремне мин "Кыш" дип атадым. Яңавылда бишенче класста укыганда, инде мин кыш турында гына түгел, җәй-көз, яз турында да шигырьләр яза башладым. Кичләрен өстәл янына утырам да, бармак белән иҗек саный-саный, сүзләр язам. 1940 нчы елны, ахрысы, газетада минем өч-дүрт юллык шигырем басылды. Ул чактагы шатлыгымны хәзер дә хәтерлим. Бу бөтен мәктәптә бер вакыйга булды. Озын тәнәфестә бик күп укучыларны линейкага җыеп, завуч Баямый Мөслимов мәкаләне кычкырып укыды.

Баямый абый кара чәчле, ягымлы, чибәр һәм шат күңелле кеше иде. Ул олы классларда татар әдәбиятын укыта иде. Укучылар да, укытучылар да аны бик ярата иде. Мин дә Баямый абыйга беркемгә

күрсәтмәгән шигырь дәфтәремне бирдем. Шигырьләрне укып чыккач, ул минем белән сөйләшеп утырды, киңәшләр бирде. Мин “шагыйрь булырга” хыялланып йөргән малай идем. Шул вакытларда укытучылар һәм башка кешеләр миңа яхшы киңәшләрен бирделәр. Алар миңа ышанмасалар яисә ялгыш сүз-киңәш бирсәләр, мин беркайчан да язучы булмас идем.

Унынчы сыйныфны бетереп, нишләргә дип йөргәндә, газетаның җаваплы секретаре Сәгъдә апа миңа университетның татар бүлегенә керергә киңәш бирде. Редакциягә Казаннан "Кызыл Татарстан" газетасы килә. "Кызыл Татарстан"да университетка укучылар кабул итү турында белдерү басылган иде. Мин документларымны Казанга, университетка җибәрдем.

1955 нче елда мин беренче романымны яздым. Аны иң элек Габдрахман Әпсәләмов укып чыкты. Ниндидер бер җыелышта ул мине мактап телгә алды. Шуннан соң яшь иптәшнең беренче романын башкалар да укыды, яратты, мактады, ләкин... бастырырга бик ашыкмады. Шулай да романым басылып чыкты.

Шулай итеп, минем алда зур әдәбият ишеге ачылды. Язучы булу өчен, күп нәрсә кирәк. Беренчедән, табигый талант һәм тырышлык кирәк. Ләкин сине аңлаучы, кирәк чакта ярдәм кулы сузучы халкың, укучың кирәк!

**21** **Әдипнең беренче әсәрләре нәрсә турында булган?**

1) туган ягының кешеләре
2) ел фасылларының матурлыгы
3) мәктәп тормышындагы вакыйгалар
4) үзенең шатлыклары

**22** **Язучының мәктәп укытучылары турында фикере нинди?**

1) Укытучыдан балаларга карата таләпчән булуы сорала.
2) Укытучының балаларга ышануы кирәк.
3) Балалар укытучы белән киңәшләшәләр.
4) Ул үзе дә укытучы булырга хыялланган.

**23** **Үзенең язучы булып китүе турында Нурихан Фәттах нәрсә әйтә?**

1) Әдәбияттагы уңышлары өчен ул һәркемгә рәхмәтле.
2) Язучы булып китәргә ашыкмаган.
3) Кешеләр аңа ялгыш сүз-киңәш биргәннәр.

4) Башка язучылар аның әсәрләрен хуплаганнар.

**24** **Нурихан Фәттах фикеренчә, язучы өчен иң мөһиме нәрсә?**

1) Әдәбиятта уңышка ирешү өчен, тырышлык кына кирәк.
2) Язучының сәләткә ия булуы җитә.
3) Укучыларының аңлый белүе әһәмиятле.
4) Укучыларыннан ярдәм соравы мөһим.

**25** **Истәлекләрендә Нурихан Фәттах нәрсә турында сөйли?**

1) Әдәби әсәрләрне бастыру турында
2) Язучы эшенең авырлыклары турында
3) Әдәбияттагы беренче адымнары турында
4) Татар әдәбиятының үсеше турында

**5 нче бүлек**

**Текстны укыгыз һәм 26-35 нче биремнәрдәге туры килгән сүзне үрнәктәгечә билгеләгез.**

**ҮРНӘК** **0** 1) бит 2) әллә **(3)** дә 4) шундый

Бүген Фәридәнең туган көне. Аның әнисе бик матур торт пешерде. Бүген Фәридәнең күлмәге (0) … бик матур. Анысын да әнисе (51) ... . Өйләре дә бик матур бүген. Бар да чиста, бар да (52) ..., бар да матур. Күр инде, өстәлдәге чәчәкләр дә (53) ... . Әнисе аларны бүген (54) ... алып кайткан. Бар да шундый матур, шундый (55) ...! Тиздән аның дус кызлары килә…

Фәридә әнисе (56) … аш бүлмәсенә керде.

- Әни, әни, әйдә әби бүгенгә генә залга, минем кунакларым янына (57) …, ә? Бүген анда бөтен нәрсә шундый матур, шундый яңа, ә әби шундый (58) …

Әнисе башта аңламады. Аннары, кинәт кенә (59) …, урындыкка утырды… “Менә нәрсә, Фәридә, дусларыңа шалтырат һәм әйт: бүген туган көнеңне (60) …”, - диде ул. Менә шулай…

**26** 1) ясады 2) җитештерде 3) текте 4) эшләде

**27** 1) уңайлы 2) иркен 3) якты 4) пөхтә

**28** 1) елмая 2) елый 3) шиңә 4) егыла

**29** 1) әллә 2) генә 3) инде 4) икән

**30** 1) сәер 2) серле 3) куанычлы 4) моңсу

**31** 1) артына 2) арасына 3) алдына 4) янына

**32** 1) булмасын 2) чыкмасын 3) китмәсен 4) карамасын

**33** 1) иске 2) дәү 3) карт 4) олы

**34** 1) рәхәтләнеп 2) сакланып 3) сагынып 4) хәлсезләнеп

**35** 1) чакырмыйбыз 2) уздырмыйбыз 3) җыелмыйбыз 4) көтмибез

## ЯЗУ

**6 нчы бүлек**

**36-40 нчы биремнәрне укыгыз. Беренче җөмләнең эчтәлегенә туры китереп икенче җөмләне язып бетерегез. Һәр җөмләдә өчтән артык сүз кулланырга ярамый. Җаваплар бланкына бары тик шул сүзләрне генә үрнәктәгечә буш ара калдырмыйча языгыз.**

**ҮРНӘК** **0** Дустымның ялга китүенә өч атна булды инде.
**Дустым ................................ ял итәргә китте.**

| | |
|---|---|
| **0** | ӨЧАТНАЭЛЕК |

**36** Мин яңа сыйныфташымнан элек кайсы шәһәрдә яшәве турында сорадым.

**Яңа сыйныфташыма шундый сорау бирдем: « Элек син ...................?»**

**37** Алар район үзәгеннән ерак булмаган кечкенә авылда яшиләр икән.

**Аларның авылы кечкенә һәм район үзәгеннән .......................... икән.**

**38** Җәен авылга кайткач, әбием мине тәмле ризыклар белән сыйлады.

**Җәен мин ......................., һәм әбием миңа тәмле ризыклар пешерде.**

**39** Мин дусларыма шалтыраттым, чөнки аларны шугалакка чакырырга теләдем.

**Дусларыма шалтыратып, минем аларны ......................... килде.**

**40** Әти-әниемнең ял көннәрендә чаңгыда йөрүләренә шатланам, чөнки бу бик файдалы.

**Спорт белән ................ файдалы булганга күрә, әти-әнием ял көннәрендә чаңгыда йөриләр, һәм мин моңа бик шат.**

**7 нче бүлек**

**Сез татар дустыгыздан хат алдыгыз. Аның сорауларына җавап биреп, хат языгыз. Язма эшегез 100 сүздән торырга тиеш.**

**Бу биремне махсус бланкка языгыз.**

**41**

*... Җәйге ялда мин Санкт-Петербургка кунакка бардым. Анда тарихи урыннарны карадым. Шәһәр миңа бик ошады.*
*... Сез җәйге ял вакытында кайларда булдыгыз? Анда ниләр күрдегез? Сезгә нәрсәләр ошады?*